Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге составына керүче Сименеево пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2024 елның 4 ноябрь № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 4 ноябрьдә уздырылган «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сименеево торак пункты, Сухарево авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы? Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

– янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын төзү, ремонтлау

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 10 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 9 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 9 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге составына керүче Сименеево торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сименеево торак пункты, Сухарево авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы? Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

– янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын төзү, ремонтлау

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Сухрау авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сухрау авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Галимов

«Исполнительный комитет «Сухаревского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»